ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТУРИЗМУ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТУРИСТЛЫК БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

27.03.2017 Казан ш. № 33

Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетына аккредитацияләнгән оешмалардан Татарстан Республикасы территориясе чикләрендә урнашкан кунакханәләрне һәм бүтән урнаштыру чараларын, таудан чаңгы шуу трассаларын, комлыкларны үз эченә алучы туристлык индустриясе объектларына алар тарафыннан планлаштырылучы классификацияләүне гамәлгә ашыру турында белдерү тәртибен раслау турында

"Россия Федерациясендә туристлык эшчәнлеге нигезләре турында" 1996 елның 24 ноябрендәге 132-ФЗ номерлы Федераль законның 3.2 статьясының сигезенче абзацы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Туристлык индустриясе объектларын классификацияләүне гамәлгә ашыручы оешмаларны аккредитацияләү буенча вәкаләтле орган турында" 2011 елның 29 августындагы 726 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитеты мәсьәләләре" 2014 елның 12 апрелендәге 234 номерлы карары нигезендә боерык бирәм:

1. Кушымта булып килүче Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитетына аккредитацияләнгән оешмалардан Татарстан Республикасы территориясе чикләрендә урнашкан кунакханәләрне һәм бүтән урнаштыру чараларын, таудан чаңгы шуу трассаларын, комлыкларны үз эченә алучы туристлык индустриясе объектларына алар тарафыннан планлаштырылучы классификацияләүне гамәлгә ашыру турында белдерү тәртибен расларга.
2. Бу боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Рәис С.Е.Иванов

Татарстан Республикасы
Туристлык буенча дәүләт
комитетының 27.03.2017
№ 33 боерыгы белән
расланды

Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетына аккредитацияләнгән оешмалардан Татарстан Республикасы территориясе чикләрендә урнашкан кунакханәләрне һәм бүтән урнаштыру чараларын, таудан чаңгы шуу трассаларын, комлыкларны үз эченә алучы туристлык индустриясе объектларына алар тарафыннан планлаштырылучы классификацияләүне гамәлгә ашыру турында белдерү
тәртибе

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетына аккредитацияләнгән оешмалардан Татарстан Республикасы территориясе чикләрендә урнашкан кунакханәләрне һәм бүтән урнаштыру чараларын, таудан чаңгы шуу трассаларын, комлыкларны үз эченә алучы туристлык индустриясе объектларына алар тарафыннан планлаштырылучы классификацияләүне гамәлгә ашыру турында белдерү тәртибе "Россия Федерациясендә туристлык эшчәнлеге нигезләре турында" 1996 елның 24 ноябрендәге 132-ФЗ номерлы Федераль законның 3.2 статьясының сигезенче абзацы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Туристлык индустриясе объектларын классификацияләүне гамәлгә ашыручы оешмаларны аккредитацияләү буенча вәкаләтле орган турында" 2011 елның 29 августындагы 726 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитеты мәсьәләләре" 2014 елның 12 апрелендәге 234 номерлы карары нигезендә эшләнде һәм Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетына (алга таба – Дәүләт комитеты) аккредитацияләнгән оешмалардан Татарстан Республикасы территориясе чикләрендә урнашкан кунакханәләрне һәм бүтән урнаштыру чараларын, таудан чаңгы шуу трассаларын, комлыкларны үз эченә алучы туристлык индустриясе объектларына алар тарафыннан планлаштырылучы классификацияләүне (алга таба – классификацияләү) гамәлгә ашыру турында белдерү процедурасын, вакытларын, рәвешен, шулай ук мондый белдерүнамәләрне теркәү тәртибен билгели.

1.2. Белдерүчеләр булып классификацияләүне гамәлгә ашыру өчен Россия Федерациясе Мәдәният министрлыгының 2015 елның 29 апрелендәге 1340 номерлы боергы белән расланган Кунакханәләрне һәм бүтән урнаштыру чараларын, таудан чаңгы шуу трассаларын, комлыкларны үз эченә алучы туристлык индустриясе объектларын классификацияләүне гамәлгә ашыручы оешмаларны аккредитацияләү тәртибенә туры китереп алынган гамәлдәге аккредитацияләү аттестаты булган һәм классификацияләүне гамәлгә ашырырга планлаштыручы юридик затлар (алга таба – аккредитацияләнгән оешма) тора.

1.3. Аккредитацияләнгән оешмалардан алар тарафыннан планлаштырылучы классификацияләүне гамәлгә ашыру турында белдерүнамәләрне (алга таба – белдерүнамә) кабул итү, шулай ук кунакханәләрне һәм бүтән урнаштыру чараларын, таудан чаңгы шуу трассаларын, комлыкларны үз эченә алучы туристлык индустриясе объектларын классификацияләүне гамәлгә ашыручы аккредитацияләнгән оешмалар рееестрына (алга таба – реестр) планлаштырылучы классификацияләүне гамәлгә ашыру турында белдерүнамә җибәргән аккредитацияләнгән оешма турында белешмәләр кертү (белешмәләр кертүдән баш тарту) туристлык эшчәнлеген дәүләти җайга салу бүлегенең вәкаләтле заты (алга таба – вәкаләтле зат) тарафыннан гамәлгә ашырыла.

1.4. Вәкаләтле зат Дәүләт комитеты боерыгы белән билгеләнә.

## 2. Белдерүнамә тапшыру тәртибе һәм вакытлары

2.1. Классификацияләүне гамәлгә ашыру өчен аккредитацияләнгән оешма, классификацияләүне гамәлгә ашыра башлаганчыга кадәр 30 эш көненнән иртәрәк булмаган чорда һәм 15 эш көненнән дә соңга калмыйча, шушы Тәртипкә кушымтага туры китерелгән рәвештә, Дәүләт комитетына белдерүнамә җибәрә.

2.2. Белдерүнамә аккредитацияләнгән оешма тарафыннан ике нөсхәдә, гамәлдәге аккредитация аттестатының аккредитацияләнгән оешма җитәкчесенең яисә аның вәкиленең имзасы һәм мөһере белән таныкланган күчермәсен теркәп, турыдан-туры Дәүләт комитетына: 420015, Татарстан Республикасы, Казан ш., Максим Горький ур., 19 й адресы буенча яки, теркәлгәннәрнең исемлеген язып, тапшыру турында белдерүнамә белән, Дәүләт комитетының электрон адресына (e-mail: tourism.rt@tatar.ru) сканлаштырылган (pdf.), аккредитацияләнгән оешма җитәкчесенең яки аның вәкиленең көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган документлар рәвешендә заказлы почта хатын җибәрү юлы белән тапшырыла.

## 3. Белдерүнамәне карау һәм реестр төзү

3.1. Белдерүнамәне турыдан-туры Дәүләт комитеты адресына тапшырган очракта, аны тапшыру көне булып керә торган документ сыйфатында теркәлү көне санала. Белдерүнамәне заказлы пачта хатын җибәрү юлы белән юллаганда, аны тапшыру көне булып Дәүләт комитеты тарафыннан почта хатын алу көне санала. Белдерүнамәне электрон почта аша җибәргәндә, аны тапшыру көне булып белдерүнамәнең Дәүләт комитеты тарафыннан Татарстан Республикасының бердәм ведомствоара электрон документ әйләнеше системасында теркәлгән көне санала.

3.2. Белдерүнамәнең бер нөсхәсе Дәүләт комитетында кала, ә икенчесе аккредитацияләнгән оешмага белдерүнамәне беркетелгән керү номеры белән теркәгән көнне тапшырыла (белдерүнамәдә күрсәтелгән фактик адрес буенча җибәрелә).

3.3. Белдерүнамәне электрон почта аша тапшырган очракта вәкаләтле зат аны теркәгән көнне аккредитацияләнгән оешмага белдерүнамәдә күрсәтелгән электрон почта буенча белдерүнамәне алу турында дәлилләмә җибәрә.

3.4. Вәкаләтле зат белдерүнамәне карап тикшерә һәм белдерүнамә Дәүләт комитетында теркәлгән мизгелдән башлап эш көннәрендә исәпләнә торган җиде көнлек чорда реестрга белешмәләр кертә.

3.5. Аккредитацияләнгән оешма турында белешмәләр кертүдән баш тарту өчен нигезләр булып түбәндәгеләр санала:

аккредитацияләнгән оешма турында тулы булмаган белешмәләр тапшыру;

тапшырылган белдерүнамәнең шушы Тәртиптә билгеләнгән рәвешкә туры килмәве;

белдерүнамәне шушы Тәртиптә билгеләнгән чорларны бозып тапшыру.

3.6. Аккредитацияләнгән оешма турында шушы Тәртипнең 3.5 пунктында каралган белешмәләрне реестрга кертүдән баш тарту өчен нигезләр булган очракта, аккредитацияләнгән оешма адресына, белдерүнамә Дәүләт комитетына кергән көннән башлап биш эш көне дәвамында, баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, Дәүләт комитеты тарафыннан реестрга белешмәләр кертүдән баш тарту турында язмача хәбәрләмә җибәрелә. Белдерүнамә аккредитацияләнгән оешма тарафыннан белдерүнамәне кайтарып бирү өчен сәбәпче булган сәбәпләр юкка чыгарылганнан соң Дәүләт комитеты тарафыннан яңадан карауга кабул ителә һәм шушы Тәртип нигезендә яңадан карап тикшерелә.

3.7. Белдерүнамәдә, шулай ук аның нигезендә, реестрда түбәндәге белешмәләр күрсәтелә:

3.7.1. Аккредитацияләнгән оешманың тулысынча аталышы;

3.7.2. Аккредитацияләнгән оешманың адресы (юридик һәм фактик);

3.7.3. Аккредитацияләнгән оешма җитәкчесенең фамилиясе, исеме, атасының исеме, элемтә телефоны, электрон почта адресы;

3.7.4. Төп дәүләт теркәвенә алу номеры;

3.7.5. Салым түләүченең аерым номеры;

3.7.6. Аккредитация турында аттестат номеры һәм гамәлдә булу чоры;

3.7.7. Классификацияләүне гамәлгә ашыруның планлаштырыла торган датасы;

3.7.8. Классификациясен гамәлгә ашыру планлаштырыла торган, Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан кунакханәләрне һәм бүтән урнаштыру чараларын, таудан чаңгы шуу трассаларын, комлыкларны үз эченә ала торган туристлык индустриясе объектының (яки объектларының) аталышы.

3.8. Реестр вәкаләтле зат тарафыннан электрон рәвештә алып барыла, Дәүләт комитетында саклана һәм Татарстан Республикасы территориясендә классификацияләүне гамәлгә ашыручы аккредитацияләнгән оешмалар турында белешмәләр формалаштыру һәм тапшыру өчен билгеләнгән.

3.9. Вәкаләтле зат реестрда булган белешмәләрнең "Интернет" мәгълүмати-телекоммуникацияләр челтәрендә Дәүләт комитетының рәсми сайтында (www.tourism.tatarstan.ru) "Файдалы мәгълүмат" бүлегендә аларны реестрга керткән көннән башлап эш көннәрендә санала торган ике көнлек чорда урнаштырылуын тәэмин итә.

3.10. Реестрда булган белешмәләр ачык һәм гомуми файдалана торган булып санала.

3.11. Дәүләт комитеты, оешу-хокукый рәвешенә һәм милекчелек рәвешләренә бәйсез рәвештә, оешмаларның язмача яки телдән гарызнамәләре

буенча, гарызнамә кергән мизгелдән башлап эш көннәрендә санала торган ике көнлек чорда, аккредитацияләнгән оешмалар турында реестрда булган белешмәләрне бирә яисә күрсәтелгән белешмәләрнең булмавы хакында хәбәр итә.

3.12. Белдерүнамәләрне теркәгән, язуларны реестрга керткән һәм реестрда булган белешмәләрне биргән өчен түләү алынмый.

3.13. Аккредитация турында аттестатның гамәлдә булу чоры тәмамлангач аккредитацияләнгән оешма турында мәгълүмат Дәүләт комитеты тарафыннан реестрдан төшереп калдырыла.

3.14. Реестрдан төшереп калдырылган аккредитацияләнгән оешма, яңа чорга аккредитация турында аттестат алганнан соң, Тәртипкә туры китереп, белдерүнамәне яңадан җибәрә.

Татарстан Республикасы
Туристлык буенча дәүләт
комитетының 27.03.2017
№ 33 боерыгы белән расланган
Татарстан Республикасы
Туристлык буенча дәүләт
комитетына аккредитацияләнгән
оешмалардан Татарстан
Республикасы территориясе
чикләрендә урнашкан
кунакханәләрне һәм бүтән
урнаштыру чараларын, таудан
чаңгы шуу трассаларын,
комлыкларны үз эченә алучы
туристлык индустриясе
объектларына алар тарафыннан
планлаштырылучы
классификацияләүне гамәлгә
ашыру турында белдерү тәртибенә
кушымта

Рәвеше

Татарстан Республикасы территориясе чикләрендә урнашкан кунакханәләрне һәм бүтән урнаштыру чараларын, таудан чаңгы шуу трассаларын, комлыкларны үз эченә алучы туристлык индустриясе объектларына планлаштырылучы классификацияләүне гамәлгә ашыру турында

БЕЛДЕРҮНАМӘ

____________________________________________________________

(юридик затның тулысынча һәм кыскартылган исеме)

____________________________________________________________

(ИНН, ОГРН, оешманы теркәү адресы, ш.и. почта индексы)

____________________________________________________________

(оешманың фактик адресы, ш.и. почта индексы)

____________________________________________________________

(җитәкчесенең вазыйфа аталышы, ФИА, телефоны, электрон почтасы)

____________________________________________________________

Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитетына хәзергесе белән Татарстан Республикасы территориясе чикләрендә урнашкан кунакханәләрне һәм бүтән урнаштыру чараларын, таудан чаңгы шуу трассаларын,

комлыкларны үз эченә алучы туристлык индустриясе объектларына планлаштырылучы классификацияләүне гамәлгә ашыру турында белдерә, гамәлдә булган _______________ _______________, _______________________________________
(документ номеры) (бирү датасы) (аккредитация аттестатын бирүче
__________________________________________________________тарафыннан бирелгән
органның исеме)
аккредитация аттестаты булуын раслый.

Татарстан Республикасы территориясендә туристлык индустриясе объектларын классификацияләүне гамәлгә ашыручы түбәндәге оешмалар турында мәгълүматны Реестрга кертүне сорыйм:

| № п/п | Туристлык индустриясе объекты аталышы | Классификацияләү чорлары | Белдерелгән категориясе |
|---|---|---|---|
| 1. | | | |
| 2. | | | |

Тапшырылган мәгълүматның дөреслеген гарантиялим.

Кушымта: аккредитацияләнгән оешманы аккредитацияләү турында аттестат күчермәсе.

Персональ мәгълүматларны эшкәртүгә риза.

«___» ____________ 20__ел.

____________________________ _______________ _____________________
(юридик зат җитәкчесенең яисә юридик зат вәкиленең вазыйфа аталышы) (имза) (имзаның аңлатмасы)

Белдерүнамә кабул ителде

______________ ________________________ _______________ _____________________
(дата) (вазыйфа) (имза) (имзаның аңлатмасы)